РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЗНАКАЕВО
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул. Ленина, д.14, г. Азнакаево, 423330

Ленин ур.,14 нче йорт, Азнакай ш., 423330

Тел./факс(885592)7-15-50,7-00-37; E-mail:aznakay@tatar.ru, adm-aznakay@mail.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 сентябрь 2019 ел № 31

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 20.12.2012 ел №86-24 карары белән расланган Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү хакында (24.11.2014 №146-41, 25.08.2015 №174-48, 17.03.2016 №20-5, 25.08.2016 №32-8, 09.12.2016 №38-11, 29.09.2017 №56-18, 22.08.2018 №108-27, 13.12.2018 №121-29, 23.05.2019 №136-33 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законга таянып, Азнакай шәһәренең Җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү комиссиясенең 13.09.2009 ел карары нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 20.12.2012 ел №86-24 карары белән расланган Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (24.11.2014 №146-41, 25.08.2015 №174-48, 17.03.2016 №20-5, 25.08.2016 №32-8, 09.12.2016 №38-11, 29.09.2017 №56-18, 22.08.2018 №108-27, 13.12.2018 №121-29, 23.05.2019 №136-33 карарлар редакциясендә) үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләүгә керешергә.

1.1. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында:

- Азнакай ш., М. Солтангалиев ур., 26 йорт адресу буенч аурнашкан 16:44:010116:175 кадастр номерлы, мәйданы 1580 кв. м булган территориаль зонаны, коммуналь объектлар зонасыннан (КО) Д3 җитештерү һәм эшмәкәрлек эшчәнлеге алып бару өчен кирәкле объектларга хезмәт күрсәтү зонасына үзгәртергә.

- Азнакай ш., М. Солтангалиев ур., 17Б йорт адресу буенча урнашкан, 16:44:010116:1382 кадастр номерлы, мәйданы 213 кв.м булган җир участогы өчен территориаль зонаны коммуналь объектлар зонасыннан (КО) Д3 җитештерү һәм эшмәкәрлек эшчәнлеге алып бару өчен кирәкле объектларга хезмәт күрсәтү зонасына үзгәртергә.

- Азнакай ш., М. Солтангалиев ур., 16:44:010116:25 кадастр номерлы, мәйданы 93 кв.м. булган, район шәһәр мунчасы территорриясендә урнашкан №23 гараж территориясен, коммуналь объектлар зонасыннан (КО) Д3 җитештерү һәм эшмәкәрлек эшчәнлеге алып бару өчен кирәкле объектларга хезмәт күрсәтү зонасына үзгәртергә.

2. Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проектны әзерләү буенча эш тәртибен һәм срокларын билгеләргә (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Җитәкче М.И. Солтанов

Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре Башкарма комитеты
карарына кушымта №1
№ ____ от ________2019 ел

**Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча әзерлек эшләрен үткәрүнең тәртибе һәм вакыты**

| N | Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү буенча эшләрне үткәрү тәртибе | Эшләр башкару вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Азнакай шәһәренең Җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү эшләрен оештыру. | 2019ел III квартал |
| 2.<br>2.1.<br>2.2. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү һәм килештерү.<br>Җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә һәм картографик материалларга үзгәрешләр кертү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны килештерүдә катнашучы хезмәтләр һәм ведомстволар кисәтүләренә шәрехләр әзерләү. | 2019 ел III-IV кварталлар |
| 3.<br>3.1.<br>3.2.<br>3.3.<br>3.4. | Азнакай шәһәре җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча фикер алышу<br>Ачык тыңлаулар үткәрү.<br>Җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проектка үзгәрешләр кертү.<br>Күрсәтелгән проектны һәм аңа мәҗбүри кушымталарны (ачык тыңлаулар беркетмәсе һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә) Башкарма комитет җитәкчесенә тапшыру.<br>Азнакай муниципаль районы башлыгына әлеге проектны шәһәр Советына раслауга яки кире кагу турында карар кабул итү өчен, Азнакай шәһәре төзелешләренең җирдән файдалану Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проектны Азнакай муниципаль районы Башлыгына юллау, аны кабат тәкъдим итү датасын күрсәтеп, эшләп бетерү өчен җибәрү турында Карар кабул итү өчен җибәрү турындагы проектны Азнакай муниципаль районы Башлыгына юллау. | 2019ел IV квартал |